Нәкыйп Каштанов

Канатлы чәчәкләр

Шигырьләр, әкиятләр,
табышмаклар, санамышЛар

Казан • Татарстан китап нәшрияты • 2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос = Тат) -5
К 34
Рәссамы АЛЛА АЙСИНА
КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН
**Каштанов Нәкыйп**

Канатлы чәчәкләр: Шигырьләр, әкиятләр, табышмаклар, санамышлар.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.— 64 б.

«Канатлы чәчәкләр» — шагыйрь Нәкыйп Каштановның балалар өчен иҗат иткән сигезенче китабы. Биредәге мавыктыргыч, йөгерек телле, самими, нәфис сурәтле шигырьләр күңелләргә канат куя.

Издание для детей и юношества

Каштанов Накип Фасхутдинович

**КРЫЛАТЫЕ ЦВЕТЫ**

*Стихи, сказки, загадки, считалки*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х. Корбанов*. Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова.* Корректоры *С.Н.Мифтахова*. Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.03.2004. Форматы 60□90 $^1/_8$. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 8,0 + форз. 0,50. Шартлы буяу-оттиск 35,0. Нәшер-хисап табагы 6,91 + форз. 0,88. Тиражы 5000 экз. Заказ Э-209. Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19. **http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru.** Оригинал-макет Jahatтм программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahatтм. «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

ISBN 5–298–01407–0

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## * * *

«Мине җый,— ди. Башка төшә
Йомры нарат күркәсе.—
Әбиеңнең самавырын
Мин генә гөжләтәсе».

Җыяр идем мин аларны,
Наратта кәнфит үссә.
«Чәй янына без кирәк»,— дип,
Кәнфитләр башка төшсә...

# ЧИШМӘГӘ КЕМ БАРА?

(Әкият)

Сырхаулап китте әбекәй,
Йөткерә дә төчкерә.
«Чәй эчсәм генә,— ди ул,—
Тәннәремә көч керә.

Сихәтле чәй кайнатырга
Чишмә сулары кирәк.

Хәлем юк алып кайтырга —
Чишмә авылдан ерак.

Оныгыма кушар идем,
Бигрәкләр дә бәләкәй.
Күтәреп кенә йөртмәле —
Сабый әле, балакай...»

Әбинең йон оегына
Сырпаланып,
Каелып
Телгә килде кара Песи:
«Мин булганда —
кайгың юк...

Чишмәләрнең иң тәмлесен,
Сихәтлесен мин беләм:
Тирә-ягы аның яшел —
Мүктән тукылган келәм.

Чәйгә суны алып кайта
Алыр идем, боерсаң.
Тик юк минем Акбайныкы
Кебек матур муенсам».

«Һау, һау,— диде Акбай,—
һау, һау,
Әбекәем, бул син сау.
Муенсам бар.
Тик юк минем
Кәҗәнеке сыман бау.

Чиләккә бау тагар идем,
Чумырып су алыр идем.
Чишмә төбе — тере су:
Шундук савыгыр идең...»

«Аллага шөкер,— ди Кәҗә,—Бавым да бар,
Муенчак та.
Мин ярдәм дә итә алам
Әбигә авыр чакта.

Чишмә юлы — минем сукмак,
Һәр сикәлтәсен беләм.
Чәйгә салып эчәр өчен
Өзәләм шифа үлән.

Тик кайтканда...
Адашам мин,
Сакал корсын, алдашсам!
Сыерныкы сыман шөлдер
Кирәк миңа, адашсам...»

«Му-у, му,— дип сузды Сыер,—
Әбигә кирәк су-у.
Чишмәдән су эчкәнем бар,
Суы, һай, йөгерек су.

Муенчак та,
Аркан да бар,
Шөлдерем дә бар минем,
Тик суны түкми кайтырга
Юк шул минем иярем».

«Ми-ха-хай! —
дип кешни Бахбай,—
Сүз куертканчы алай,
Ияремә менсен әйдә,
Әбием, синең малай.

Йөгереп кенә барырбыз,
Чишмәдән су алырбыз!
Песи, Акбай, Кәҗә, Сыер —

Самавырга салырсыз!»

* * *

Юл читендә чәчәк
Керфекләрен ачты.
Юлдагы күләгә
Тузан белән качты.

Нур сирпелә башлый
Юлдагы һәр эздән.
Назланып ята юл —
Әни кайтыр тиздән.

# ӨЙ НИК ЯКТЫ?

— Көн ник якты?
— Кояш елмайганга...
— Төн ник якты?
— Ай елмайганга...
— Өй ник якты?
— Әни елмайганга...

# ТАБЫЛГАН ИПИ

Төшеп китте идәнгә,
Үпкәләде ипи.
Мәрьям аны ашамый,
«Прәннек кирәк»,— ди.

Телевизордан күреп сорый:
— «Баонти» ал, әни!
«Бэм-эм-дэмс» ал,

«Сникерс» ал,
Баллы йогурт ал! — ди.

Ике ягы шоколадлы
Печенье сорый.
— Пирожное белән бергә
«Чупа-чупс» та ярый!

— Алдындагын аша, кызым,—
Дип әйтә әнисе.
...Телевизордан килә кебек
Чәчәкле торт исе...

Телевизор карый-карый
Ачыгылды шулай.
Ипигә май ягып ашый
Экрандагы малай.

Шундый тәмле итеп ашый,
Куя рәхәт көлеп.
Дөньядагы иң татлысы
Шул ипидер кебек.

Бик тиз табып алды Мәрьям
Югалган ипиен.
— Иң тәмлесе ипи икән,
Рәхмәт, әнием!

# СИГЕЗЕНЧЕ МОГҖИЗА

Дөньядагы могҗизалар
Җиде, диеп әйтәләр:
Мисыр пирамидалары,
Таҗ Мәһәлләр...

Җидесен дә сез белерсез.
Сигезенчесе — үзем:
Йокларга яткач йомылмый,
Телевизор карый күзем...

## ТЫҢЛАМАСАМ

Әти чыбык чыж-ж-жлата,
Әни тел белән кисә...

Ә миннән җилләр исә!

## МАЙ КОҢГЫЗЫ

Майның җылы киче.
Әни сыер сава.
Ага урамнардан
Парлы сөттәй һава.

Күтәрелә җирдән
Яшел үлән исе.
Баш өстендә йолдыз —
Инде дисбе-дисбе.

Шомырт чәчәкләре
Эңгердә дә яна.
Җемел-җемел исе
Урам буйлап ага.

Чирәмнәргә ятып
Инде җил дә тына.
«Жу-жу» килеп оча
Май коңгызы гына.

Өйалдында ятам

Май коңгызын тыңлап.
Нигә көндез очмый,
Ник оча ул соңлап?

Тәрәзәмә коңгыз
Килеп-килеп кага.
Йокы алып килгән
Йомры канатында.

## ЙОКЫ

Кем ул анда әйләнә,
Бишеккә гел бәйләнә?
— Әлли-бәлли,
бәбкәем,— дип,
Йокы мәллә сөйләнә?

Йокы мәллә сөйләнә,
Матур көйләр көйләнә.
Әлли-бәлли-бәү итә,— дип,
Төшләр булып төйнәлә.

Йокы төшкә төйнәлә,
Әлли-бәлли-бәү.
Әйләнгәләп йөрмә, йокы,
Йоклыйбыз, әйдә, икәү.

## КЕМ ТӨШЕНӘ НИ КЕРӘ?

Тавык төшенә тары керә.
Сыер төшенә печән керә.

Бахбай төшенә солы кирә.
Мәче төшенә тычкан кирә.
Маэмай төшенә сөяк кирә.
Куян төшенә кишер кирә.

Малай төшенә ни кирә?
Алма бакчасы кирә.
Ә кыз төшенә ни кирә?
Анысын ул үзе генә белә!

# МАҖАРАЛЫ ТӨШЛӘР

***1. Әби сөйләгән әкиятләрне күзләр леп-леп итеп йомылганчы тыңлап яткач күргән төш***

Хуҗа Насретдин
Йөгерә бар тыннан
Тәгәри киткән
Йомгак артыннан.

Аждаһа куа
Кырык каракны.
Шүрәле урлый
Алтын таракны.

Убырлы карчык
Кага чабата.
Сертотмас үрдәк
Йөзә корабта.

Себерке оча

Синбадны алып.
Орчык бөтерә
Алпамша алып.

Су анасының
Кулында чукмар.
Кычкыра миңа:
«Күрәсең юк-бар!

Уян тизрәк,
Төшләрең — хата».
...Аяк очымда
Мендәрем ята...

### *2. Телевизордан сугыш турында кино карагач күргән төш*

Офыклардан килә
Арба арты арба.
Авыр арбаларны
Кара атлар тарта.

Офыклардан чыгып,
Офыкларга бара
Кара атлар тарткан
Арба арты арба.

Кара атлар арган,
Атлар йончыганнар.
Арбаларда бара
Авыр кара чаннар.

Тәгәрмәчләр җиргә
Батып-батып бара.
Күз яшьләрен ташый
Арба арты арба...

### *3. Зоопарктан кайткач күргән төш*

Аю янына
Читлеккә кереп,
Баласын алдым
Күлмәккә төреп.
Еланнарны да
Урыйм муенга.
Бүре баласын
Тыгам куенга.
Сыерчык мәллә —
Сызгырам үзем.
Бөркетнекедәй
Бик үткен күзем.
Никтер шул мизгел
Уяндым үзем.
Төшнең хикмәте
Хакында сүзем:
Карыйм, куйнымда,
Мыр-мыр-мыр итеп,
Мәче йоклый ич,
Изерәп китеп.

### *4. Умартачы Салих бабайның бакчасыннан алма өзеп ашагач күргән төш*

Салих бабай бакчасының
Алмагачы алмалы.

Тик биектә алмалары,
Баскыч белән алмалы.

Корт күчләре җыя торган
Баскычы бар бабайның.
Алмагачка сөяп куйсаң,
Өзәргә була Айны.

Нинди малай
булыйм ди мин,
Алма өзеп алмагач.
Менеп киттем
баскыч буйлап,
Үсеп китте алмагач.

Баскычым да үсә бугай.
Аратасы гел арта.
Уч төбендә кебек
авыл —
Караган идем артка.

Умартачы баскычының
Бар мәллә сихри көче —
Бал кортлары кебек гөжли
Янымда йолдыз күче.

Алмагачның яфракларын
Араласам — алма юк.
Югарыда сыңар алма
Тора бары елмаеп.

Юкә балы сыман сары,
Тубал кебек түгәрәк.
Бер ботактан бер ботакка
Күчеп йөри тәгәрәп.

Менеп җиткәч, аңлап алдым
Умартачы бабайны:
Алмагачка алма итеп
Тагып куйган ул Айны.

### *5. Бәрәңге бакчасында кү-ү-үп итеп эшләгәч күргән төш*

Әбиләр чуагы
Килеп җиткән, имеш.
Мин бәрәңге казыйм,
Күлмәкчән килеш.

Өстемдә нигәдер
Ак йокы күлмәге.
Бәрәңге бакчасы
Бүлмәле-бүлмәле.

Мин алган кишәрлек
Йокы бүлмәм, имеш.
Карават башыннан
Агып ята инеш.

Әни кайтып килә
Куалап бәрәнне.
Ә күктәге кояш —
Сап-сары бәрәңге.

Җирне казый-казый
Кызып киткән килеш,
Ул бәрәңгене мин
Күккә аткан, имеш.

Зур бәрәңге төбен
Каердым да аттым —
Килеп чыкмасынмы
Йоп-йомыры алтын.

Кеше күргәнче дип,
Учыма кыстым да
Тизрәк тыгып куйдым
Мендәрем астына.

Әни күргән, ахры —
Тавышы сөенә:
«Тизрәк тор, улым,
Бәрәңге суына.

Бәрәңге суына,
Тизрәк тор, улым!»
Күзне ачсам:
Мендәр
Астында бер кулым...

Төш булдымы?
Өнме?! —
Кулны алмый яттым.
Кулны алсам, килеп
Чыгар сыман алтын...

### *6. Корбан бәйрәменнән соң күргән төш*

Килә сарык көтүләре
Салават күпереннән.
Ак йоннары болыт кебек
Күперенгән.

Китә алар күк катына.

Карап калам куанып.
Тәкәләрнең мөгезләре —
Сирень куагы...

* * *

Йокы, йокы, йокыкаем,
Татлылардан татлы ла:
Төшләремә төшәм, диеп,
Күктән йолдыз атыла.

# АЙГА СӘЯХӘТ

Галәмдә — эт, тагын әлләниләр...
Нигә миңа Айга очмаска?!
«Төшләр күле» ярларына басып
Карап тору кызык ич аска!
Ау тавының менеп кыясына
Нигә туган җиргә бакмаска?!
Туган йортның газизлеген тоеп,
Нигә Айдан очып кайтмаска?!
Ай дөньясын барып күрү өчен
Төрле-төрле уйлар корамын.
Хыялларым чынга ашсын өчен
Төзеп куйдым Галәм корабын.
Кораб эче җылы, уртада мич,
Ягулыгы, ышан,
су гына.
Морҗасыннан Ай күренеп тора —
Аптырамыйм компас югына.
Утырам мин кереп корабыма,
Мич башында урын уңайлы.
Чыккач-чыккач Галәм киңлегенә,
Урап кайтыйм мәллә шул Айны.

Әллә очтым,
Әллә очмадыммы —
Мич башында йоклап кителгән.
Хактыр Айга барып кайтуларым —
Кораб тиеп Аем кителгән...

## ЙОРТ ИЯСЕ

Малайларның,
Кызларның
Озак йоклап ятканын,
Алардан башка җилнең
Таң капкасын какканын,
Алардан башка гына
Сызылып таң атканын
Сөймим лә,
Сөймим, сөймим.
Юрганнарын тарткалыйм,
Алып-алып аткалыйм,
Мәче булып мияулап,
Яннарына яткалыйм —
Йорт иясе лә,
Йорт иясе мин!

Малайларның,
Кызларның
Елый-елый торганын,
Киенергә кирәктә,
Башка тартып юрганын,
«Авыртам, әни!» — диеп,
Хәйлә-мәйлә корганын
Сөймим лә,
Сөймим, сөймим.
Ишекне шакылдатам,

Телефон шалтыртам,
«Табиб апаң килгән!» — дип,
Әнисеннән алдатам —
Йорт иясе лә,
Йорт иясе мин!

Малайларның,
Кызларның
Оеклар эзләткәнен,
«Киенә белмим!» — дип,
Әбисен тезләткәнен,
«Ашыйсы килми!» — дип,
Ашны гаҗизләткәнен
Сөймим лә,
Сөймим, сөймим.
Оекларны табышам,
Тузаннарын кагышам,
Өстәлдәге ботканы
Җәһәт кенә кабышам,
Ишек төбенә кадәр
Озатыша барышам —
Йорт иясе лә,
Йорт иясе мин!

# ТӘЛИНКӘ БЕЛӘН КАШЫК

(Әйтеш)

***1***

— Минем белән ашап була,
Була хәтта баш кашып.
Табынга аш ашыктырам,
Өстәлне шакылдатып.

Минем белән уйнап була,

Көй чыгарам: шык та шык.
Агач кашык булсам да мин,
Кулларда — алтын кашык.

Син, тәлинкә, мин булмасам,
Җамаякка әйләнәсең...

*2*

— Алтын кашык башың белән
Ник миңа бәйләнәсең?

Өстәлләрдә мин тормасам,
Түгәрәк булмый табын.
Мин булмасам, кашык та юк,
Сиңа ни кирәк тагын?

Миндә — чәкчәк, коймак, бәлеш,
Гөбәдия, кыстыбый.
Син аларны төшеңдә дә
Күргәнең юк, телең тый.

Итне миндә пычак кисә,
Кыяр чәнчи чәнечке.
Син әйтмешли,
чәшке дә мин —
Кичә Мәрьям чәй эчте.

Син кителсәң: «И хәерсез,
Бигрәк юка», — диләр.
Мин ватылсам,
зарланмыйлар —
Өйгә бәхет юрыйлар.

*3*

...Яле, Мәрьям, аш аша.
Кашыгың белән тәлинкәң
Юкса озак талаша.

# ИҢ ҖИТЕЗ КҮЛӘГӘ

Иң җитез күләгә
Кемнеке,
Нинеке?
— Атныкы?
— Кошныкы?
— Этнеке?
— Җилнеке?..

Иң җитез күләгә
Түгелме болытта:
Җилдерә кайчакта
Машина булып та,
Самолет булып та,
Көнгерә булып та...

Синдәме, Җир шары,
Иң җитез күләгә? —
Төн булып
Күчә ул
Илләрдән илләргә...

Җитезнең җитезе
Вакыт диләр мәле? —
Әгәр елгыр вакыт
Булса күләгәле,
Аның күләгәсе —

Җитезнең җитезе:
Үзе тоттырмый да,
Күренми дә үзе.

Шулай да
Вакытны
Мин узам чак кына,
Бишле алып өйгә
Җилдергән чагында.

— Иң җитез күләгә
Инде ул кемнеке?
Белмичә торсагыз,
Әйтермен:
— Ми-не-ке!!!

## МИНЕМ ПЕСИ

— Әгәр тычкан куян булса?..
— Аны сикереп тотар өчен
Минем песи күз йомганчы
Булыр иде селәүчен.

— Әгәр тычкан буйвол булса,
Карап торса каш астыннан?..
— Минем песи каушап калмас,
Шундук булыр арыслан.

— Әгәр тычкан антилопа
Булып җилдә ял кабартса?..
— Куып җитәр минем песи,
Егып салыр леопардча.

— Әгәр тычкан зебра булып,
Чапса батып кара тиргә?..
— Эһ иткәнче куып тотар
Минем песием — пантера.

— Әгәр тычкан дәү фил булса,
Беркем җиңә алмас аны!
— Фил колагына оя корыр
Минем песи — кыр тычканы...

## СОРАВЫНА — ҖАВАБЫ

— Океанның филе бармы?
— Баш катырма әле, кит.
— Беләсеңме, океанның
Филе бик дәү,
Ул — кит!

— Юлбарысы буламы соң?
— Ник булмасын, бик була.
Өер-өер балыкларны
Кыйрап йөри
Акула!

— Ә менә ат юктыр анда,
Төшмәс диңгез катына.
— Утырып йөри балыклар
Диңгез атына!

— Төлке, куян, аю, поши —
Алар бармы бөтенесе?!
— Ник булмасын, булгач хәтта
Диңгез керпесе.

# ТОЗСЫЗ ШИГЫРЬ

Тоз салсаң
Елгага —
Диңгез була
Елга да.

Булса да
Елга тездән —
Балык үрләр
Диңгездән.

Кылыч балык,
Ат балык,
Өер-өер
Вак балык.

Бер-берсен
Уза-уза,
Килер скат
Һәм медуза.

Киләчәк
Дельфиннар да
Безнең белән
Уйнарга.

Акула да
Киләчәк,
Куркытып
Йөриячәк.

Фонтан атып
Болытка,
Киләчәк

Олы кит та.

Ташбака
Килеп җитәр,
Малайлар
Аны җигәр.

Диңгезле
Булу ансат,
Тау кадәрле
Тоз тапсак...

## ШИКӘР КОМЫ ЧҮЛЕ

Шикәр комы чүлендә
Аклыктан күз камаша:
Ак барханнар өстендә
Ак болытлар — тамаша.

Баллы кәлтә кымшанмый да,
Гүя тора сакта ул.
Офыкларга карый кебек
Шикәрләнгән саксаул.

Беркем килми ялтыр чүлгә,
Үтми хәтта дөяләр дә.
Машиналар килсен иде
Шикәр комы төяргә.

Һәркемгә дә җитәрлек ул,
Кирәк бары алырга.
Җитә хәтта һәр балага
Шикәр йортлар салырга.

Шикәр-шикәр
шәһәр корып
Була мондагы комнан.
Нигә соң,
Нигә соң
Шикәр алмыйлар
моннан?!

Бәлки, шикәр комы чүлен
Бөтенләй белмиләрдер?
Белмәгәнгә күрә генә
Бу чүлгә килмиләрдер.

Ак саксаул телгә килде:
«Киләләр дә... төйиләр.
Чүл кадәр чүлне ничек
Күтәрсен ди дөяләр?!

Ком җитә комсыз башына —
Монда меңләп кеше бар.
Әйләнә шикәр комына
Монда килгән кешеләр...»

# ДҮРТ ТИЕН

Бер тиен,
Тагын өч тиен.
Киткәннәр, ди, кибеткә.
«Дүрт тиенгә ни тия?» — дип,
Син аларны тилмертмә.
Бер тиен алган — чикләвек,
Өч тиен алган — банан.
«Сникерс» алгач та әле

Акчалар бераз калган.
Ышанмыйсың, көләсеңдер:
«Бу абый алдый!»— диеп.
Әйтсәм әйтим:
Бер тиен дә,
Өч тиен дә —
Чын Тиен.

# ТӨНГЕ УРМАН

Күктә — йолдыз,
Карурманда
Тычкан уты җемелди:
«Без янганда бөҗәкләргә
Юлны табу җиңел»,— ди.

Үләннәрне иеп үрли
Яшел утлы коңгызлар:
«Без кайчандыр күктә идек,
Без — атылган йолдызлар...»

# ҖӘЙ

Сандугач
Сайрап туа.
Сайрар урын
Сайлап туа.

Якты көннәр
Көлеп туа.
Шәфәкъләрен

Күреп туа.

* * *

Ай —
Йомарлам май...

## СУ АНАСЫ БАЙЛЫКЛАРЫН БАРЛЫЙ

Күлем тирән, казанлы.
Казанлы да сазанлы.

Җәеннәрем мыеклы,
Елык-елык койрыклы.

Табан балык алтынлы,
Айдан алган алтынны.

Бәртәсләрем көмешле,
Тәңкәләре килешле.

Алабугам энәле,
Үзем бирдем энәмне.

Кызылканат — уйнагым,
Тәңкәләре — уймагым.

Су өстендә маймычлар,
Чуртан килсә, таймычлар.

Шыртлакалар төркеме
Өркетерлек һәркемне.

Кәрәкәләр гаскәре,
Зөбәрҗәтем фәсләре.

Ә бакамы?!
Ә бака...
Чү, тукта!
Кояш калка!

# ЧЕРКИЛӘР

Көннән соң
Төн җылынып,
Җәйләр җитте исә,
Без дә без килеп черкиләр
Колакларны кисә...

Без дә без, диләр, без дә без,
Үзгәртми җыр-көйне.
...Күпме тыңлап ишетмәдем
«Мин» дигән черкине.

# ТӨНБОЕК

### *1*

— Күл төбендә
Йоклыйсың син
Төн буе,
Төн боегып
Кала синсез,
Төнбоек.

Чәчәгеңдә
Көн яктысын
Күтәреп,

Айлы күлнең
Өсләренә
Күтәрел.

Су өстендә
Ай сурәте
Тирбәлер.
Төн яктысы
Айда түгел,
Синдәдер.

Син калыксаң,
Йолдыз читкә
Коелмас —
Чәчәгеңә
Тулыр энҗе
Һәм алмаз.

Таң атканда
Йолдызларны
Алып син,
Күл төбенә
Төш, төнбоек,
Ял ит син.

***2***

— Төнбоексыз
Булыр иде
Көн боек.
Исемем дә
Көнбоекмы? —
Төнбоек!

Чәчәгемдә
Кояш йоклый
Изерәп.
Мин калыксам,
Таңнар ата
Тизерәк.

Минем белән
Бергә калка
Кояш та.
Күрәсезме,
Тамчылар бар
Кояшта.

Су өстенә
Канат җәйсә
Кичке таң,
«Кайт, кояш!» — дип,
Бытбылдыкны
Кычкыртам.

Уйнап туймас
Күбәләктәй
Кайта ул.
Чәчәгемнең
Мендәренә
Ята ул.

Бакаларым
Җырлап аны
Йоклата.
Кояш белән
Күл төбенә
Мин батам.

Шауламагыз,
Кояш йоклый
Лабаса.
Нәрсә булыр
Төнлә кояш
Уянса?!

## КҮЛДӘВЕК

Бу шәһәрнең уртасында
Инеш тә юк, күл дә юк.
Бала-чага чупылдарга
Ярый мин бар — күлдәвек.

Эссе кояш астында
Кибәсемне беләм мин.
Шулай да йөзем чытмыйм,
Кояш белән көләм мин.

Чәчрәп-чәчрәп елмаям,
Елмаерга чамам бар:
Корып кибә башласам,
Яңгыр тели балалар.

## МӘЧЕ ЯҢГЫР ТЕЛӘГӘН

Мәче бүген тырнаша,
Тырышыпмы-тырыша.

Ятакта да ул ауный —
Сүземне искә алмый.

Ни булган икән аңа?
Ник сукмый мине санга?!

Карап-карап торам да —
Яңгыр ява урамда.

* * *

Яңгыр, яу,
Яңгыр, яу
Әти чәчкән арышка —
Үсеннәр биш карышка!

Сеңдереп яуган өчен,
Син, яңгырым — тырышка,
Кыяр бирермен кичен.

Яңгыр, яу,
Яңгыр, яу
Әни чәчкән кабакка —
Кабак булсын табактай!

Сибәләп яуган өчен
Син, яңгырым — өлгергә,
Җиләк бирермен кичен.

Яңгыр, яу,
Яңгыр, яу
Үзем чәчкән борчакка,
Үссә — сыем курчакка.

Чиләкләп койган өчен
Син, яңгырым — җитезгә,
Алма бирермен кичен.

Яңгыр, яу,
Яңгыр, яу,
Яланаяк йөрермен —
Үсү серен белермен.

# КҮБӘЛӘК ҺӘМ КҮБӘЛӘК КОРТЫ

И көлә күбәләк:
— Кара әле көлкене,
Бар эше ашау да
Ашау бу төкленең.

— Күбәләк, күбәләк,
Күрсә дә күзкәең,
Мин төкле, шыксыз зат
Булачак үзкәең.

* * *

Бәлешеңне, кишер, яратам мин.
Үс әле, үс, татлы тамырым —
Әниемнең күәс чиләгендә
Күтәрелә инде камыры!

* * *

Чәчәк кенә өзгән кәҗә,

Салам түбәгә менгән —
...Мөгезенә кояш элгән.

## КӘККҮК

Карурманда аваз:
— Кәк-күк, кәк-күк, кәк-күк.
Кайтавазлар дәшә:
— Күп-күп, күп-күп, күп-күп.

Кәккүк гомер саный:
Сиңа кирәк күпме?
Бер гомер сора син,
Сорама күпне...

## МАКТАНЧЫК ЧЕБЕН

«Югары утырам!» — дип
Әйтеп бетерми сүзен,
Мактанып җилпенгәндә,
Җил алып китә үзен.

## А-ДАШ-КАН

«А-у-у, а-у-у»,—
дип карурманда
Кем ауылын эзли анда?

## КОЯШ ЯФРАК АСТЫНДА

Җиргә кояш төшкән —
Җир җиләге пешкән:
Табан пешәр — бас кына.
Кояш яфрак астында.
Таңнар ата гел моннан —
Кояш монда төн кунган.

## ӘҺӘ-ҺӘЙ!

— Һәй! — дип кычкырдым,
Миңа урап кайт, аваз!
Алды-китте тавышымны
«Әһә-һәй»ләп кайтаваз.

Яңгыравык канатына
Утыртты да очты ул.
Тау башларын,
карурманны,
Болыннарны кочты ул.

Хәлсезләнеп, ах-ух килеп,
Урап кайтты кайтаваз:
«Мә, ал,— диде,—
тик торма син,
Күп йөртәлмим, куәт аз».

## КИКРИКЛЕ ГӨМБӘ

Кәрҗин тотып кулыма
Урманга киттем кереп.
Абага арасыннан
Кычкыралар:

— Кик-ри-күк!
Бәтәч —
Әтәч!
Каян монда — урманда?!
Карасам: кикрикле
Әтәч гөмбәсе анда...

## БЕЛӘ ӘНИСЕ...

«Бал» дисәң, бер кими бал.
Тел тисә, ике кими.
Өч кими бармак тисә,
Дүрт кими калак тисә...

«Тими минем улым,
Сорамый балга тими»,—
Дисә дә, белә әнисе:
Низамида бал исе...

## КРОКОДИЛ,
## ӘЛЛӘ ТЕЛЕҢ ЙОТТЫҢ?

— Әй, крокодил, крокодил...
Ник сөйләшмисең?
— Әллә тәмле йоттың?
— Әллә ачу йоттың?
— Әллә телең йоттың?..

## * * *

Әйтче, әни,

Нигә бабай
Сүз әйтсәм дә елмая?
— Чукраклар, улым, шулай
Күздән эзли,
Әйткән сүзгә киная...

— Әни, әни,
Бабай кебек
Елмаймыйсың син нигә?

— Аллага шөкер,
Колагым
Каты түгел әлегә.

— Әни, әни,
Ачуланма!
Колагың синең каты —
Мине бер дә ишетмисең,
«Алып бир!» — дисәм татлы.

# ЯҢА ФАТИР ҺӘМ МИЧ

Куаныштык сеңелем белән,
Дөньяларыбыз матур.
Бирделәр безгә бу җәйдә
Өр-яңа иркен фатир.

Кояш төшкән бүлмәләре
Безгә көлеп карыйлар.
Миче юк икән фатирның —
Гармундай батарейлар.

Көз килүен сизмәдек тә,
Суынды өй — йөткертә.
Югарыдан әмер килгән:

— Ягарга әле иртә!

Эх, безнең элекке фатир,
Миченә яга торган,
Югарыдан хәбәр көтми
Утыны яна торган.

Акшарларын коймый гына
Алып килик шул мичне:
Назласын җылысы белән,
Иркәләсен һәр кичне.

## ҖИЛНЕҢ ӨЕ

Өй саласы килә җилнең —
Шакмаклары юк аның.
Шуңа җыя яфракларның
Көзге яңгыр юганын.

Калын имән яфракларын
Нигез-таш итеп тезә.
Озын-озын тал яфрагын
Ниргәлеккә дип өзә.

Дивар итеп яфрак өйгәч,
Дүрт якка тәрәз уя.
Челтәрле миләш яфрагын
Тәрәзә итеп куя.

Сары чирәп итеп тезә
Юкәнең яфракларын.
Морҗа итеп бастыра ул
Яфракның катыракларын.

Инде өйгә керер өчен

Ишекне уярга кая?..
Каенның куш яфрагын
Пар ишек итеп куя.

Элә зирек алкаларын —
Серле кыңгырау әзер.
Хозур яфрак-өйгә кереп
Йокларга була хәзер.

## КӘРҖИН БЕЛӘН ЧҮП ЧИЛӘГЕ

(Әйтеш)

***1***

— Сине көтеп үтә
Минем күп вакытым,—
Дип дәште кәрҗингә
Беркөн чүп савыты.—

Кибетләрдән урап
Тулып кайтканыңны
Сагынып көтәм дә...
Өметләнәм тагы.

— Сагынуың әйбәт.
Ләкин өмет итмә:
Чүп чиләге тотып
Йөрмиләр кибеткә!

— Синнән
кайтыш җирем
Бармы әллә минем?! —
Тоткам калфак кебек,
Чигүле итәгем.

Кызыл күлмәгем дә
Үземә килешле.
Кызу эшләр идем
Синең эшне.

— Кеше көләр иде,
Әгәр хуҗабикә
Сине тотып беркөн
Китсә кибеткә.

Чүп-чардан башканы
Таный да белмисең.
Аннан соң
Акчаны
Саный да белмисең.

***2***

— Кибеткә мин барсам,
Ала белер идем.
Кабыксыз бәрәңге
Таба белер идем.

Кылчыксыз,
Тәңкәсез,
Койрыксыз,
Канатсыз
Балык сатып алсам —
Икеләтә очсыз.

Кабыксыз,
Сабаксыз
Суган алсаң — арзан.
Тышсыз кыяр

Алыр идем
Базардан!

Алыр идем әле,
Кибетчене җайлап,
Карбызның,
Кавынның
Төшсезен сайлап.

Сөт,
Эремчек,
Каймак
Савытсыз да тәмле.
Кәнфит-шоколадлар
Кәгазьсез дә ямьле.
Арчылган алмалар,
Арчылган бананнар
Алып кайтсам,
Кем мине яманлар?!

— Әй, чиләк туган,
Чиләк туган,
Өйдә күп утырып
Башыңа да
Чүп тулган.

— Чыгармасаң иде
Сүземне дә чүпкә.
Бар минем сиңа
Үпкә.

Алып кайтканыңның
Яртысыннан күбе,
Дөресен әйтимме,
Чүпнең дә чүбе!

Кабык,
Сөяк,
Кылчык,
Балан-чия төше,
Шешә,
Тартма,
Капчык,
Төргәк кәгазь ише.

Ничек ризык булып
Табыннарга менсен?!
Тураган белә, диләр,
Ашаган да белсен...

Әгәр мине тыңлап
Торса хуҗабикә,
Минем белән генә
Йөрер кибеткә.

## МИҢА БИШ ЯШЬ

Марсельгә

Иртән торсам, әй гаҗәеп:
Бәллүр вазада — биш алма;
Тәлинкәмдә — биш салма;
Өчпочмагымда —
биш почмак;
Аны татлы карбыз кочмак.

Хәтта торт та биш катлы,
Һәм чәкчәге бик татлы.

Гел биш тә биш,
Гел биш тә биш —

Нигә бу алай икән?!
Бүген нинди сер бар,
дисәм,—
Мин зур үскәнмен икән.
Миңа бүген —
биш яшь икән.
Биш яшь икән...

# СУЫК БАБАЙ КАР КӨРИ

Шыгыр-шыгыр суык йөри,
Суык бабай кар көри:
«Малайларга тау шуарга
Көртләр өям, кил —
күр»,— ди.

# * * *

Кар ява
Күбәләк-күбәләк...

Кар оча,
Киләсе ел печәнен
Күбәләп.

# ЯЗ

Җилдә очып йөрергә
Карлар авыр инде.
Кара җир булып ята

Карга каурые...

* * *

Үрелеп үскән талларда
Каз оясы җылысы бар.
Талның сары алкасына
Тию белән эреде кар...

* * *

Язгы карның,
Тизрәк эреп бетеп,
Килә чирәм булып калкасы:
Каз бәбкәсе мамыгыдай әнә
Талның сары алкасы...

# ТАЛ ПЕСИЛӘРЕ

Карлар инде кәрәз-кәрәз —
Бал булып кояш тула.
Талларны сырып алган
Сап-сары төклетура.

# АПРЕЛЬ

Кояш балалары булып
Җиргә сары төс иңде:
Ояларда бәбкә чыга,
Талларда — тал песие.

# БЕРЕНЧЕ КҮБӘЛӘК

Әле урамда
Котыра салкын,
Котыпта сыман
Нык тора салкын.

Шундый көннәрдә
Әллә ни булды:
Көн керфегенә
Җепшек кар кунды.

Кояш югары,
Ага гөрләвек:
Кая карама —
Уйдык күлдәвек.

Уянды, очты
Сары күбәләк.
Җиргә,
Кояшка
Үтә тигәләп.

Кунакка оча
Умырзаяга —
Заяга эзли,
Заяга.

Табалмас аны
Сары күбәләк.
Кояш эндәшә:
«Әле иртәрәк».

Күбәләк куна
Бабай кашына.

Мыгырдый бабай:
«Кая ашыга?!»

Кунды күбәләк
Минем учыма:
«Күбәләк, кунып тор,
Күбәләк, очма!

Тәүге булсаң да,
Соңладың кебек —
Яз көтә-көтә
Булдым мин көтек».

Ишетте бугай,
Аңлады сыман...
Ләкин учымнан
Очыртты буран.

Кайдан купты ул?!
Кар оча кабат.
Аларда үткен,
Зәмһәрир канат.

Күбәләгемне
Тотарлар куып.
Сары канатын
Ак итәр суык.

Өемә алып
Керәсем калган.
Эзләсәм аны
Табармын сыман.

Эзләп йөргәндә,
Шуны аңладым:

Күбәләк түгел,
Мин ул соңладым...

## ТАШУ КАЙТКАЧ

Арт бакчаның читәненә
Камыш элеп,
Ләм элеп,
Язгы ташу кайта ярга,
Күлләр кала
Бүленеп.

Язгы ташу кайта ярга —
Юа калка,
Кузгалак.
Тауда лапта сугучылар
Яр буена
Кузгала.

Кысылып калып читәнгә
Кояшта кипкән балык,
Сине суда йөздерерләр
Малайлар, табып алып.

Су буенда бик күп әле
Малайларның табары:
Тал ботагы саен көтә
Татлы камыш тамыры.

Камыш төбе
шундый кипкән:
Тешләп кенә ярмалы —
Тел йотканчы
Ашамалы,

Ап-ак онлы,
Ярмалы.

Шәрә агач тамырының
Бөгелешен күр әле:
Баш астына кулын салып,
Йоклап ята
Шүрәле.

Су буенда, шома сазда
Кама эзе,
Каз эзе;
Тагын әллә нинди эзләр —
Йөргән бугай
Яз үзе!

# КАНАТЛЫ ЧӘЧӘК

***1***

Чәчәкләрнең күбәләктәй
Килә бик тә очасы.
Болыннарны,
Болытларны
Оча-оча кочасы.

Буй җитмәгән кояшка да
Бик тә килә кунасы.
Килә йолдыз арасында,
Чыкларда коенасы.

Таҗын җилдә җилпи чәчәк,
Сабагы бар, җибәрми:

«Очмасаң да,
Минем белән
Кояшка буй җитәр...» — ди.

***2***

Өзелгән чәчәкләр
Ашыга сулырга.
Сулмасын дисәң син,
Утыртма суларга.

Таҗларын ал кулга,
Сулыш өр тын гына:
Учыңда чәчәкме —
Күбәләк кагына...

***3***

Оча чәчәк берәүләп тә,
Оча чәчәк икәүләп тә,
Оча чәчәк күбәүләп тә —
Кулга килеп кунгач кына
Әйләнәләр күбәләккә...

# Табышмаклар

## * * *

Болынга таралды ак болыт.

* * *

Усалланса, кара була.
Юашланса, ак була.
Күтәрелсә, каурый була.
Аю була, акула...
Тау-тау булып тора кайчак.
Малай була, кыз була.
Ага да җил уңаена,
Сурәтләре бозыла.
Ат та була, кош та була.
Гыйфрит булып та оча.
Кереп төрле кыяфәткә,
Күктән ага да ага.
Менә әле карап тора
Сакаллы кәҗә булып,
Аның исеме ... .

## КҮКЕЛЕ СӘГАТЬ

Тагын вакыт җитә —
Тәрәз ачылып китә,
Башын суза кәккүк
«Кәк-күк! Кәк-күк!»
Сәгать ничә?

* * *

Әле сөйли,
Әле көйли,

Әле җырлый,
Әле чыжлый.
Биемичә
Көчкә түзеп
Торам, дия.
Сез, балалар,
Ду куптартып
Биесәгез,
Мин дә биим,
Ди ... .

* * *

Хуш ислесе дә бар аның,
Җиләклесе дә бар аның,
Тик кызыгып ашый күрмә:
Кәнфит түгел, ул ... .

# САНАМЫШ

Берәү, икәү...
Мияу да мияубикәү.
Камка түткәй,
Сары түшкәй —
Песнәк.
Черки — тешләк.
Төнге Ай.
Акбай.
Юртак тай!

# БАЛЫКЧЫ КАРГА

Тездән суга кереп
Баскан да ярга,

Башын кырын салган
Кап-кара карга.
Суда коенасы
Киләме әллә?
Кара карга йөзә
Беләме әллә?
Тагын бераз кереп
Алса чирканчык,
Суга чума-чума
Уйнар ул качып.
Акчарлаклар оча,
Һаваны чарлап:
Кайлардан килгән бу
Кара акчарлак?!
Карап тора судан
Бер көтү үрдәк:
«Бак-бак та бак-бак,—
дип,—
Суга кереп бак!» — дип
Алалар үртәп.
Таллык арасыннан
Өер-өер каз:
«Кыйгак та кыйгак,—
дип,—
Җибәрик кыйнап!» — дип
Салалар аваз.
Ишетми дә карга:
Кыйгайтып муен
Карап тора суга —
Белмәссең уен...
Чукыды да суны
Сикерде ярга:
Балык тота икән
Балыкчы карга...

## ӘЙ, АККОШ...

— Әй, аккош, аккош,
Син нигә ак?
— Кыйгак, кыйгак, кыйгак,
Мин диңгез күбегендә тудым.
Мин шуңа ак. Шуңа ап-ак!

## БАЙГЫШ

Кояш баеганын
Көтә байгыш.
Аңа таң атудыр
Кояш баеш.
Эңгер төшкәч кенә
Төн башлана.
Байгыш өчен исә
Көн башлана.
Көндез ничек күрсәк,
Шулай күрә.
Төнлә генә оча
Шуңа күрә.
Күзләре ай төшкән
Төнге күлдәй.
Төнлә күрә торган
Бинокльдәй.
Күрә кебек аның
Колагы да:
Тычкан чыйкылдаса
Караңгыда,
Күреп алган кебек,
Төшә очып —
«Күзле-колаклы»дан

Булмый качып.
Тычкан тоту аңа
Шөгыль генә,
Йолдыз җыю белән
Шөгыльләнә.
Йолдыз җыя байгыш,
Күктән җыймый.
Элек җыйды күктән.
Күптән җыймый.
Ерак бер йолдызга
Очкан чакта,
Җирдә, кояш чыгып,
Таңнар ата.
Кичкә кадәр җиргә
Кайтмый йөри,
Канатлары тала,
Яна-көйри.
Кайтыр иде көндез —
Кояш күрә:
Йолдыз җыйган өчен
Шелтә бирә.
Йолдызны ул хәзер
Җирдән җыя.
Йолдыз атыла да
Китә кая?
Байгыш дөньядагы
Иң-иң бай кош:
Оясына
Йолдыз ташый
Байгыш.
Оясында мең-мең
Йолдыз яна.
Бик бай булса да ул,
Моңсу аңа.
Төнлә генә очкач

Юк дуслары:
Кемгә күрсәтсен ул
Йолдызларны?..

# БИЛГЕСЕЗ КОШ

Өй түбәсен карагыз.
Агач ябалдашларын —
Гел без белгән кошкайлар
Эзлиләр үз ашларын.

Менә алар, карагыз,
Карагыз да санагыз:
Песнәк, былбыл, сыерчык,
Карга, чәүкә һәм чыпчык.

Күгәрченнәр «гү-гү» ди,
Саесканнар сайлана.
Бөркет болыт астында
Әйләнә дә әйләнә.

Никтер менә билгесез,
Ник күренми — чәперчек?
Абага чәчәгенме
Чык белән куйган эчеп?

# КАРЛЫГАЧ ОЯСЫ

Таштан, агачтан
Салынмаган өй.
Ишеге дә юк —
Ябылмаган өй.
Пәрдәсе дә юк —
Ләкин яхшы өй.
Төньяктагы түгел,

Көньяктагы өй.
Түбәсе дә юк,
Яңгырлар үтми.
Нигезе юк,
Ишелеп китми.
Буй җитмәслек өй
Кыекта тора.
Ләмнән коелган
«Кадак»та тора.
Караваты юк —
Мамык ястык бар.
Өстәле дә юк,—
Азык, ясмык бар.
Өйдән баш суза
Бала-чагасы:
— Әни, уйнарга
Килә чыгасы!
Егылып төшсәң,
Менәрмен, димә.
Өебез биек,
Баскыч юк нигә?!

# БЫТБЫЛДЫК

Качышлы уйнарга
Чакыра бытбылдык —
Кич саен кычкыра:
«Бар идек, юк булдык».
Төштем су буена —
Уйныйк соң качышлы.
Бик озак эзләдем,
Тапмадым ул кошны.
Кычкыра таллыктан,
Үзми дә бытбылдык:

«Бар идек, юк булдык,
Бар идек, юк булдык...»
Таллыкка мин керсәм,
Кычкыра камыштан.
Камышка мин керсәм,
Җил искән ул коштан.
Кычкыра тупылдан,
Үчекли бытбылдык:
«Бар идек, юк булдык,
Бар идек, юк булдык».
Ничек соң табарга
Күренмәс ул кошны?
Кычкырам:
«Бытбылдык,
Уйнамыйк качышлы!
Куышлы уйныйк без,
Мин куып тотармын.
Әбәкле уйнасак,
Һичшиксез, отармын.
Бер күрсәт үзеңне,
Юк сине күргәнем:
Түшкәең ни төстә,
Томшыгың,
Күзләрең?
Канатың икедер,
Тәпиең дә ике,
Тик алар ниндиләр —
Күргәнем юк сине».
Хәйләмне аңлады,
Күренми бытбылдык,
Кычкыра аръяктан:
«Бар идек, юк булдык,
Бар идек, юк булдык...»
«Кайларда йөри соң,
Югалды бу бала...» —

Дип, әни басмада
Чиләккә су ала.
Качтым мин таллыкка —
Мин дә бер бытбылдык:
«Әнием, тап мине —
Бар идек, юк булдык?!»
Таллыкка ул керсә,
Мин качам камышка —
Әйләндем күзләргә
Күренмәс шул кошка.
Мин — шомырт төбендә,
Зиректә — бытбылдык.
Кычкырабыз парлап:
«Бар идек, юк булдык,
Бар идек, юк булдык».
Эңгерләр куера,
Куркыта да тагы.
Ухылдый башлады
Төн ябалагы.
Кайтыйк без өйләргә,
Бик озак юк булдык.
Сине дә әниең
Эзлидер, бытбылдык.

## ЯР КАРЛЫГАЧЫ — КЕРӘШӘ

Су буенда сары яр бар,
Кәрәз кебек тишекле —
Керәшәләр очып керә
Төклетура шикелле.
Тыз-быз оча керәшәләр —
Вакыты юк кунарга.
Бал ташыймы әллә алар —
Бал төсе бар бу ярда?
Су өстенә тия-тия,

Түшкәйләрен юешләп,
Бертуктамый оча алар —
Ял итмиләр соң нишләп?
Каршы ярда күпме тал бар
Тибрәнеп кунарга.
Ял итәргә төшим дисә,
Чирәм көтә бу ярда.
Канатыңа бераз ял бир,
Әй, тиктормас керәшә.
Ярдан аяк салындырып,
Утыр әле янәшә.
Су буенда гомер иткәч,
Балык та тотып кара,
Өйрәтәм балык әфсенен,
Әйдәле отып кара:
«Балык, кап,
Балык, кап,
Яр буенда
Ялтырап ят!»
Калкавычым күпме батты,
Керәшә көтә-көтә.
Керәшәләр ишетми дә —
Күчтәнәч салып үтә!
Керәшәләр
Көнләшәләр,
Шуңа төшмиләр бугай...
«Алар, улым, куна белми,
Оча гына...» — ди бабай.

# СИРТМӘ КОЙРЫК

Көн дә сиртмә койрык
Балык ашый куырып.

Килә җавап табасым:
Кайдан алган табасын?

Табасына май салган,
Ул майны кайдан алган?

Яр буена ут яккан —
Шырпысын кайдан тапкан?

Ничек тоткан балыкны —
Суга койрык салыпмы?

Көн дә аны күзәттем,
Күзәтеп күз бетләттем.

Табасын да тапмадым,
Тапмасын да тапмадым.

Әйдә, сиртмә койрык,
Балык ашыйк куырып.

Балык тота сиртмәле —
Миңа балык чиртмәде.

## САРЫ ЧЫПЧЫК

Әйтә кебек:
— Карыным ач,
Чырык-чырык.
Ишегалдына чыкканда,
Миңа ярма алып чык!

## КАНАТЛЫ КӨНГЕРӘ

Безнең якларда да
Яши ул көнгерә.
Соры көнгерә,
Яшел көнгерә.

Бер алга сикерә,
Бер янга сикерә:
Бер дә атлый белми —
Көнгерәме?!
Көнгерә!

Ботактан ботакка,
Коймадан коймага,
Кыектан кыекка,
Куактан куакка
Күченеп тора ул —
Көчкә күз өлгерә:
Гади көнгерәме?!
Супер көнгерә!

Сыерлар сыртында
Кояшта кызына,
Сыерчык йортында
Ызгышып тузына,
Йә комда коенып
Ул безне көлдерә:
Моңсу көнгерәме?!
Клоун көнгерә!

Җимнәр эзли-эзли
Сикереп арыса,
Елышып килүче
Песигә тарыса,
Ул очып элдерә:
Көнгерә көнләшер,

Канатлы көнгерә!

Безнең якларның да
Бар үз көнгерәсе.
Берәү генә түгел —
Санап өлгерәсе:
Миләш көнгерәсе,
Урман көнгерәсе,
Хәтта бар
Кычыткан көнгерәсе!

Безнең көнгерәнең
Никтер капчыгы юк,
Капчык кына түгел,
Хәтта
Янчыгы юк.
Баланы кибеттән
Алмаганны белә —
Ояда утыра
Безнең көнгерә!

Бер ары сикерә,
Бер бире сикерә.
Учыңа сыймалы
Мини көнгерә.
«Нәрсә соң ул?» — диеп,
Башыңны бетермә.
«Чырык-чырык» килеп,
Ул үзен белдерә.
Канатлы көнгерә!

# КӨРТ ЭЧЕНДӘ КӨРТЛЕКЛӘР

Карурманга барган чакта,
Абый миңа сөйләде:
«Көрт эчендә көртлекләр бар,
Көрт эчендә өйләре.
Салкыннардан чатнап торса
Шәфәкътагы балкышлар,
Биек агач башларыннан
Көрткә чума ул кошлар.
Көрткә чума ышык эзләп —
Кар эчендә җылы бар.
Көрт өсләрен бозлар тотса,
Чыга алмый җылыйлар».
Чаңгыларым туктап калды,
Күңел куйды кузгалып:
Мин кызгандым көртлекләрне —
Көрт өсләре бозлавык...
Әллә инде үземдә дә
Әсир калган кош җаны —
Ишетелә кебек әнә
Көртлекнең елаганы:
«Канатларны җәеп кабат
Очалмабыз микәнни?
Ябалдашта таң җилләрен
Кочалмабыз микәнни?
Боз астында түзем җитә,
Әмма сулыш җитәлми...»
Абый инде әллә кайда —
Кузгалам мин дә ары.
Кабаланып бозны тишә
Чаңгымның таяклары...

* * *

Ишетәсеңме көрт эчендә

Гөрләвекләрнең агышын?
Ишетәсеңме көртлекләрнең
Язгы гөрләвек тавышын?!

Көрт эчендә гөр-гөр көртлек.
Көрт эчендә йөр, йөр, көртлек,
Көрт эчендә эзләр сал син
Гөрләвекне йөгертерлек!..

## КЫР ТАВЫГЫ

Кырда печән чаба бабай,
Покослары — чакрым.
Җиләкле җир тапкан саен
Ала мине чакырып.

Дәшә әнә: «Җиләкләрнең
Канатлысы табылды.
Бер кишәрлек чапмый үттем:
Анда — кыр тавыгы...»

Кыр тавыгы күргәнем юк.
Өй тавыгы шикелле
Ак микән ул,
Чуар микән,
Бармы икән сипкеле?

Канатларын кагынса да,
Оча белми торгандыр.
Тотыйм әле кыр тавыгын,
Кырда йөреп аргандыр.

Бабай әйткән кишәрлекне
Ничәнче кат таптадым.

Эзли-эзли күзем арды —
Кыр тавыгын тапмадым.

Бабай көлә: «Син тавыкның
Эзләп йөрмә карасын.
Үлән, чәчәк төсендә ул,
Күңел биреп кара син».

Үчекләп үрчи дә үрчи
Кигәвеннәр безләве:
«Җиләк эзләү түгел сиңа
Кыр тавыгын эзләве!»

Күрдем ике чык бөртеге,
Шундый тере үзләре.
Чык түгел лә,
Күзләр бит бу,
Кыр тавыгы күзләре.

Ә гәүдәсе кайда аның? —
Аңламый тордым башта.
Чуар яфрак дигәннәрем
Кош лабаса, кош ла!

Яфракларга охшар өчен
Сулышын тыя сыман.
Селкенми дә кыр тавыгы,
Береккән оясына.

Җиләкләрнең канатлысы
Табылды бит, табылды!
Тотып алыйм дигән идем —
Очты
Кыр тавыгы.

Оясында дүрт йомырка,
Дүртесе дә сипкелле.
Моңаешып тора алар
Сабый бала шикелле.

Ник куркыттым мин
кошкайны?!
Әгәр урап кайтмаса,
Матур чуар чебиләре
Тумый кала лабаса...

Читкә китеп, оя корып,
Башка йомырка салмас.
Чебиләрен ияртеп тә
Кырларда йөри алмас.

Моңсу булып китте миңа,
Күзләрдән яшь агылды.
Әйдә, бабай, китик моннан,
Кайтсын кыр тавыгы...

## ЧУМГАЛАК

Җилсез көннең камышыдай
Селкенми дә калкавыч.
Хет син кунып уят аны,
Камка тутый — камкавыч.
Урама, су чикерткәсе,
Калкавычка тисәнә:
«Күңел өчен селкенеп ал,
Син — калкавыч»,— дисәнә.
Килче, маржа көянтәсе,
Калкавычка төш әле.
Читтә йөзеп йөрмәсеннәр,

Балыкларга дәш әле.
Бабайның да калкавычы
Йоклап ята изерәп.
Төшләрендә балык күреп,
Селкенми дә әзрәк.
Аргы ярда кайсы малай
Оныткандыр кармагын:
Калкавычы бата-калка —
Чүт йөгереп бармадым.
— Бабай, бабай!
Аргы ярда
Калкавычны күр әле.
— Күптән аны
күзәтәм мин —
Кармак сала Шүрәле.
— Ә Шүрәле ник күренми,
Качтымы әллә бездән?
— Әнә бит, басып тора ул,
Суга кергән дә тездән.
— Әй, бабам, шаяртма әле,
Суда тора корган тал.
— Корган талдан
куркып торма,
Бар, кармакны барып ал.
Их, калкавыч дигәнем дә
Булган икән алдавыч:
Канатларын тиз-тиз кагып,
Очып китте калкавыч.
Бабай көлә:
— Калкавычтай
Торса да гел чумгалап,
Ул калкавыч түгел, улым,
Үрдәк бит ул — Чум-га-лак.

# ЯЗНЫ АЛЫП КАЙТЫРГА

Күл башына җитәр боз.
«Кыйгак-кыйгак» итәрбез,
Көньякларга китәрбез.
Матур җирләр үтәрбез.

«Кыйгак-кыйгак» итәрбез,
Кояшлы язны алып,
Бик тиз кайтып җитәрбез...
Көтәрсезме?
— Көтәрбез!

# ЭЧТӘЛЕК

«Мине җый,— ди. Башка төшә...»
Чишмәгә кем бара? (Әкият) .......
«Юл читендә чәчәк...» .......................
Өй ник якты? .......................................
Табылган ипи .......................................
Сигезенче могҗиза ............................
Тыңламасам .........................................
Май коңгызы .......................................
Йокы .....................................................
Кем төшенә ни керә? .....................
Маҗаралы төшләр ............................
«Йокы, йокы, йокыкаем...» ................
Айга сәяхәт .........................................
Йорт иясе ............................................
Тәлинкә белән кашык (Әйтеш)..
Иң җитез күләгә .................................
Минем песи .........................................
Соравына — җавабы .......................
Тозсыз шигырь ....................................
Шикәр комы чүле ..............................
Дүрт тиен .............................................
Төнге урман ........................................
Җәй .......................................................
«Ай...» ...................................................

Су анасы байлыкларын барлый ..
Черкиләр ............................................
Төнбоек ..............................................
Күлдәвек .............................................
Мәче яңгыр теләгән ..........................
«Яңгыр, яу...» ......................................
Күбәләк һәм күбәләк корты ...........
«Бәлешеңне, кишер, яратам мин...»
«Чәчәк кенә өзгән кәҗә...» ..............
Кәккүк ...................................................
Мактанчык чебен ..............................
Ад-аш-кан ...........................................
Кояш яфрак астында ........................
Әһә-һәй! ..............................................
Кикрикле гөмбә .................................
Белә әнисе... ......................................
Крокодил, әллә телең йоттың? .......
«Әйтче, әни...» ...................................
Яңа фатир һәм мич ...........................
Җилнең өе .........................................
Кәрҗин белән чүп чиләге (Әйтеш) .....................................................
Миңа биш яшь ...................................
Суык бабай кар көри .......................
«Кар ява...» ........................................
Яз ..........................................................
«Үрелеп үскән талларда...» ............
«Язгы карның...» ................................
Тал песиләре .....................................
Апрель .................................................
Беренче күбәләк ...............................
Ташу кайткач ....................................
Канатлы чәчәк ...................................
Табышмаклар ....................................
Санамыш ............................................
Балыкчы карга ..................................
Әй, аккош... .......................................
Байгыш ...............................................
Билгесез кош ......................................
Карлыгач оясы ..................................

Бытбылдык ............................................
Яр карлыгачы — керәшә .................
Сиртмә койрык ...................................
Сары чыпчык .......................................
Канатлы көнгерә .................................
Көрт эчендә көртлекләр ..................
«Ишетәсеңме көрт эчендә...» ..........
Кыр тавыгы ..........................................
Чумгалак ...............................................
Язны алып кайтырга ...........................